**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 102** **28.05.2018**

**«Җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 99 номерлы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. «Җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 99 номерлы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның хезмәтенә түләү айлык акчалата түләү рәвешендә башкарыла. Акчалата түләү күләме 2 нче кушымтада бирелә. Айлык акчалата бүләкләүдән тыш, җирлек башлыгына өстәмә рәвештә билгеләнә:

- айлык акчалата бүләкләүнең 38,75 проценты күләмендә айлык акчалата түләү;
- нигезләмәнең 2.3 пунктында билгеләнгән күләмдә тиешле еллар эшләгән өчен акчалата бүләкләүгә айлык өстәмә».

1.2. 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Сармаш-Баш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://zainsk.tatarstan.ru/rus/sarmashbashskoe.htm) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Авыл җирлеге**
**башлыгы урынбасары** **Н.Н. Арсланова**

Зәй муниципаль районы
Сармаш-Баш авыл җирлеге
Советының 2018 елның 28
маендагы 102  номерлы карарына
кушымта

Сармаш-Баш авыл җирлеге башлыгына
акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 15300.0 |